# Хәбәр һәм аның белдерелүе

Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аның белән бәйләнеп килә торган икенче баш кисәк **хәбәр** дип атала

1.Мин кая гына барсам да, гүзәл шәһәремАрчаны  сагынып кайтам.

2.Шәһәребез көннән-көн матурлана, зурая, үсә.

**<u>Хәбәр</u>**

нишли?
нишләде?
нишләр?
нишләгән?
күпме? нинди?

# Белдерелүе

| | |
|---|---|
| Район үзәгенә кадәр башта автобуста кайттым. Анда кайтканда ук үзебезнең Күлле авылы кешеләре белән таныштым. Дөресрәге алар мине үзләре эзләп таптылар. Күллегә кайтуымны белгәч, кемгә дә кемгә дип гаҗәпләнделәр. *(Фәүзия Бәйрәмова).* | Минем сагынып кайткан урыным – болын. Шул болында мине көтеп торучы – ул. *(Фәүзия Бәйрәмова).* Алты алтың – утыз алты. Сүзнең хуҗасы – авыз. Аталы бала – аркалы, Аналы бала – иркәле |

# Хәбәр

## Фигыль хәбәр

фигыль белән генә белдерелә

## Исем хәбәр

фигыльдән кала башка сүз төркемнәре белән белдерелә

# Төзелеше

| | | |
|---|---|---|
| а) Рушания болан каршына атлады.<br>Б) Безнең бабай бик юмарт. | А) Агайның сүзләрен Раушания гаҗәпсенеп тыңлап торды.<br>Б) Кыз сискәнеп күзләрен ачып җибәрде. | А) Ул үз-үзен кулга алырга өлгерде. |

**Гади хәбәр** → Бер сүз белән генә белдерелә

**Кушма хәбәр** → Ике як берничә сүз белән белдерелә

**Тезмә хәбәр** → Таркалмый торган сүзтезмәләр белән белдерелә